КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 6 октябрь г.Казань № 801

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Россия Федерациясенең Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясенең Гражданлык кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 елның 21 февралендәге 134 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2022 ел, 8 апрель, 332 нче карарының Россия Федерациясе Җир кодексының 56[6] статьясындагы 13 пунктында билгеләнгән гамәлдә булу срогы чыгуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районында «Хлебодаровка – Анины Салманы» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Салман авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, 16:06:000000:37 кадастр номерлы, 12 281 956 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегеннән барлыкка кигән, «Восточная Земельная Компания» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) милкендә булган, 31 292 кв.метр мәйданлы, 16:06:000000:1264 кадастр номерлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районындагы Салман авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләүләр күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

3. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләмен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә билгеләүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин